| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Бимского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Бима авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2019 Бима авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Бима авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Бима авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 15 октябренә 15 сәгать 00 минутта билгеләргә
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «I төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, Бима авыл җирлеге Бима авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә, Сез ризамы:

1. Бима авылының Пролетарская, Хезмәт, М. Горький урамнарындагы юлларны ремонтлау һәм вак таш җәю.
2. Бима авылын су белән тәэмин итү өчен тирән насослар һәм материаллар сатып алу, ремонтлау.
3. Бима авылы урамнарын яктырту өчен яктырткычлар һәм лампалар сатып алу.
4. Бима авылы урамнарын кардан чистарту.

5. Янгын сүндерү автомашинасын карап тоту, ремонтлау, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Бима авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Бимского сельского поселения
Бима авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002621

В.В. ШАМЕЕВ